| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |
|---|---|---|

| ПРИКАЗ | | БОЕРЫК |
|---|---|---|
| _20.08.2018__ | Казан ш. | № ___69_____ |

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 27 декабрендәге 105 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертү буенча конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карарын үтәү максатында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмә раслау хакында» 2016 елның 27 декабрендәге 105 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2017 елның 13 октябрендәге 110 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә (алга таба – Инспекция) конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22

статьясы (алга таба – Федераль закон), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы указлары нигезендә үткәрелә.»;

1 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 1.8 пункт өстәргә:

«1.8. Инспекциядә конкурс оештыру «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Кадрларның бердәм мәгълүмат системасы) файдаланып гамәлгә ашырыла.»;

2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Инспекция башлыгы карары нигезендә ел саен конкурс комиссиясенең составы яңартылып тора.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен тиешле таләпләргә җавап бирә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында каралган чорда әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәвенә бәйле рәвештә, шулай ук граждан хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләмәләре булу сәбәпле гражданин (граждан хезмәткәре) конкурста катнашуга кертелми.»;

IV бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле $4.1^1$ пунктын өстәргә:

«$4.1^1$. Конкурс процедуралары барышында кандидатларны бәяләү өчен бәяләүнең кимендә өч методы кулланыла: тест уздыру, анкета уздыру һәм шәхси әңгәмә.»;

түбәндәге эчтәлекле $4.3^1$ пунктын өстәргә:

«$4.3^1$. Кандидатлар конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм конкурс комиссиясе утырышын үткәргәндә башлык карары нигезендә видеога һәм (яки) аудиога яздыру эше яки тиешле конкурс процедураларын уздыруның стенограммасы алып барыла.»;

4.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.1. Беренче этапта Инспекциянең дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләре бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурсны үткәрү турында мәгълүмат әзерли һәм Инспекциянең рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра. Конкурс уздыру турында белдерүдә түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

- граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының аталышы;
- әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре;
- граждан хезмәтен узу шартлары;
- тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты;
- күрсәтелгән документлар кабул ителә торган чор;
- конкурс уздыруның күздә тотылган датасы;
- аны уздыру урыны һәм тәртибе;
- бәяләү методлары турында белешмәләр;
- граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентының вазыйфаи бурычларын, хокукларын һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыгын үз эченә ала торган нигезләмәләре, граждан хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлегендә файдалылык һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре;
- федераль порталда урнаштырылган беренчел текстка сылтама;
- башка мәгълүмат материаллары.

Конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турындагы игълан һәм конкурс турындагы мәгълүмат шулай ук вакытлы басма матбугатта бастырылырга мөмкин;

гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә;

гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен (һөнәри белем дәрәҗәсен, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажын яки белгечлеге буенча эшләү стажын (тәҗрибәсен), әзерлек юнәлешен, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәрен һәм күнекмәләрен) тикшерә.

Конкурсның беренче этабы документларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән башлана һәм 21 көннән ким булмаган чорда тәмамлана.»;

4.4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4.9. Тест уздыруны оештыру Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Инспекциядән Кадрларның бердәм мәгълүмат системасына килгән заявкалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тест уздыру өчен заявка Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында конкурс комиссиясе утырышына кадәр кимендә ике атна калгач формалаштырыла.

Тест уздыру Татарстан Республикасы Президентының «ТР дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар өчен тест уздыруны

оештыру мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган Тест уздыру методикасына туры китереп гамәлгә ашырыла.»;

4.4.10 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Шәхси әңгәмә нәтиҗәләрен бәяләү 10 баллы система буенча гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелгән баллар әлеге пунктта билгеләнгән максималь баллның кимендә 50%ын туплаган кандидат шәхси әңгәмәне узган булып санала.

Кандидат белән шәхси әңгәмә тәмамланганнан соң конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы конкурс бюллетенена 5 нче кушымтага туры китерелгән формада кандидатны бәяләү нәтиҗәсен кертә»;

түбәндәге эчтәлекле 4.4.11, 4.4.12, 4.4.13 пунктчаларын өстәргә:

«4.4.11. Анкета уздыру граждан хезмәтенең конкурс уздырыла торган вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме) буенча вазыйфаи бурычлардан, шулай ук аталган вазыйфаларны биләү өчен квалификация таләпләреннән чыгып төзелгән сораулар нигезендә уздырыла.

Анкетага элегрәк гамәлгә ашырылган профессиональ эшчәнлек кысаларында вазыйфалар буенча үтәлә торган вазыйфаи бурычлар, профессиональ казанышлар, кандидат катнашкан чаралар (проектлар, форумнар, семинарлар һ.б.), басма матбугатларда аның мәкаләләре, мавыгулары турында, шулай ук кандидат тарафыннан тапшырылырга мөмкин булган тәкъдимнәр турында һәм (яки) тәкъдим хатлары турында сораулар кертелә.

Анкета уздыру нәтиҗәләрен бәяләү 5 баллы система буенча гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелгән баллар әлеге пунктта билгеләнгән максималь баллның кимендә 50%ын туплаган кандидат анкетаны узган булып санала.;

4.4.12. Кандидатның ахыргы баллы кандидатка конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан шәхси әңгәмә, анкета уздыру нәтиҗәләре буенча куелган балларның һәм кандидатның тест узу нәтиҗәсендә туплаган балларының уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә.;

4.4.13. Кандидатларның йомгак балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе сәркатибе кандидатлардан рейтинг билгели.»;

4.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре 6 нчы кушымтага туры китерелгән формада граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары һәм 7 нче кушымтага туры китерелгән формада кадрлар резервына керүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рейтингтагы урыны, конкурс комиссиясе әгъзаларыннан кандидатларга бирелгән тавышлар саны, кандидатлар дәгъва белдергән вазыйфа караган структур бүлекчә җитәкчесенең (Инспекция җитәкчелегенең) фикере Инспекциядә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар

резервына кертүгә) кандидат турында карарны кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып тора.»;

3 нче кушымтаның 2.4, 2.5 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Граждан хезмәте стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата граждан хезмәткәрләренә граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кирәкле булган квалифкация таләпләре:

граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалары төркемендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә өч еллык граждан хезмәте стажы яисә белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча кимендә дүрт еллык эш стажы;

граждан хезмәте вазыйфаларының төп төркемендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – белгечелек, ззерлек юнәлеше буенча кимендә ике еллык граждан хезмәте стажы яки эш стажы;

граждан хезмәтенең әйдәүче вазыйфалары төркеменең «җитәкчеләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә бер еллык граждан хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике еллык эш стажы.

Граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркемендә «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)», «белгечләр», «тәэмин итүче белгечләр» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен, граждан хезмәтенең өлкән һәм кече вазыйфалар төркемнәренең барлык категорияләре өчен граждан хезмәте стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре куелмый.

Граждан хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук федераль дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфалар төркемнәрендәге вазыйфаларда, хәрби вазыйфаларда һәм бүтән федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфа төркемнәренең муниципаль хезмәт вазыйфаларында, бүтән вазыйфаларда эшләү стажы федераль законнарга туры китереп исәпкә алына.»;

2.5. Граждан хезмәтенең вазыйфаларының төп төркемендәге «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендә һәм граждан хезмәте вазыйфаларының төп төркемендәге «белгечләр» категориясендә граждан хезмәте вазыйфаларын эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган фәнни дәрәҗәгә ия булган затлар биләгәндә шушы Таләпләрнең 2.4 пунктында билгеләнгән граждан хезмәтенә яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре дәүләт органы җитәкчесенең карары нигезендә исәпкә алынмаска мөмкин.»;

3 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2.8 һәм 2.9 пунктларын өстәргә:

«2.8. Әгәр граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентында белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кирәкле таләпләр билгеләнсә, ул вакытта белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә күрсәтелгән стажга әлеге белгечлек, әлеге әзерлек юнәлеше буенча гражданин (граждан хезмәткәре) белем турында һәм (яки) күрсәтелгән белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификация турында документ алган вакыттан башланган эш чорлары кертелә.

2.9. Әгәр граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентында белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре каралмаган булса, ул вакытта белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә гражданинның (граждан хезмәткәренең) граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәр һәм күнекмәләр алганда башкарылган эш чорлары ул граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килә торган дәрәҗәдәге профессиональ белем турында документ алганнан соң күрсәтелгән стажга кертелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 5, 6, 7 кушымталарны өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 5 нче кушымта

**Конкурс бюллетене**

«___» _______________ 20___ел.
(конкурсны уздыру датасы)

___________________________________________________________________________
(аны биләү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфаның тулысынча аталышы,

___________________________________________________________________________
яки кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменең аталышы)

Шәхси әңгәмә уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатка бирелгән балл

(Белешмә өчен: максималь балл ________ балл тәшкил итә)

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Балл | Куелган баллга кыскача дәлилләмә (зарурлык булганда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |

___________________________________________________________________________
(конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме) (имзасы)

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 6 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе**

**КАРАРЫ**

___________________________________
(дәүләт органының аталышы)
«____»_________________20__ ел.
(конкурс уздыру датасы)

1. Утырышта _____ конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

| Конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфасы |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылды

_____________________________________________________________________
(структур бүлекчәсен күрсәтеп, вазыйфаның аталышы)

3. Кандидатларны рейтинг буенча бәяләү нәтиҗәләре

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Актыккы балл | Рейтингтагы урыны (кими бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

4. Конкурста җиңүчене билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (барлык кандидатлар буенча тутырыла)

| (рейтингта беренче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| (рейтингта икенче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| (рейтингта өченче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә аңлатмалар (зарурлык булганда)

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

5. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе киләсе кандидатны конкурста җиңүче итеп таный

| Җиңүче дип танылган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы |
|---|---|
| | |

6. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге кандидатларны дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә киңәш итә

| Дәүләт органының кадрлар резервына кертү өчен киңәш ителгән кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфалар төркеме |
|---|---|
| | |

7. Конкурс комиссиясе утырышында түбәндәге комиссия әгъзалары катнашмады

______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
______________________________________________

Конкурс комиссиясе рәисе ________________ ___________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасары

__________ ___________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе
сәркатибе
______________ ___________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясенең
бәйсез экспертлары

__________ ___________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Иҗтимагый совет
вәкилләре

__________ ___________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе ________________ ___________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясенең
башка вәкилләре

__________ ___________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)»;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә 7 нче кушымта

**Дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы**

**БЕРКЕТМӘСЕ**

____________________________________________

(дәүләт органының аталышы)

«____»__________________20__ ел.

(конкурс уздыру датасы)

1. Утырышта _____ конкурс комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.

| Конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфасы |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең түбәндәге вазыйфалар төркеме буенча дәүләт органының кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылды

______________________________________________________________

(вазыйфалар төркеменең аталышы)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

3. Кандидатларны рейтинг буенча бәяләү нәтиҗәләре

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Актыкка балл | Рейтингтагы урыны (кими бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

4. Дәүләт органының кадрлар резервына кертү өчен кандидатны (кандидатларны) билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре (бәяләү йомгаклары буенча максималь баллдан кимендә 50 процентын алган кандидатлар буенча тутырыла)

| ___________________________________ (рейтингта беренче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| ___________________________________ (рейтингта икенче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

| ___________________________________ (рейтингта өченче урынны яулаган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | |
|---|---|---|---|
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «тавыш бирмәде» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмгысе | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә аңлатмалар (зарурлык булганда)

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

5. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе дәүләт органының кадрлар резервына кертү өчен түбәндәге кандидатны (кандидатларны) билгеле

| Җиңүче дип танылган кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфалар төркеме |
|---|---|
| | |

6. Конкурс комиссиясе утырышында түбәндәге комиссия әгъзалары катнашмады

______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
______________________________________________________________________

Конкурс комиссиясе рәисе ________________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасары
________________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясе
сәркатибе ______________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Бәйсез экспертлар ______________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Иҗтимагый совет
вәкилләре
____________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

конкурс комиссиясе
вәкилләре ________________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)

Конкурс комиссиясенең
башка вәкилләре
______________ ________________________
(имза) (фамилия, исем, ата исеме)».

2. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык вазыйфаларын
башкаручы И.Ф. Сафиуллин